ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирин Батыршин, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Сирин Батыршин урамы, 33йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
№ 4 17.01.2021 ел

**Кәрәкәшле авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, « Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында » 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына карата, 2021 елның 14 декабреннән 1 санлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Кәрәкәшле т.п. халык җыены карарын, 2021 елның 15 декабреннән 3 санлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Салкын чишмә авылында халык җыены карарын, 2021 елның 15 декабреннән 5 санлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Ак чишмә авылында халык җыены карарын,2021 елның 16 декабреннән 7 санлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Урал т.п. халык җыены карарын, тормышка ашыру максатларында, Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Кәрәкәшле авыл җирлеге гражданнарының кушымта итеп бирелгән үзара салым акчасы җыю Тәртибен расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендына, Ютазы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм http:pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырырга .

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Дәүләтгәрәев

Кушымта 1
Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитеты
карарына
2022 елның 17 гыйнвары, № 4

**Кәрәкәшле авыл җирлегенең гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Кәрәкәшле авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Кәрәкәшле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган гражданнарның үзара салым акчалары гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә 2021 елның 1 гыйнварыннан 20 мартына кадәр вакытта түләнә.

3. Түбәндәге игътибарга лаек сәбәпләр булганда:

а) яшәү урыны буенча озак вакыт булмау,

б) авыру,

гражданнарга гариза нигезендә, өч айдан да артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (белдерүнамә) бланкы мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук кул кую яки почта элемтәсе чарасына юллау юлы белән халыкка җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Кәрәкәшле авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша почта күчерү (хисап оешмалары) юлы белән башкарыла.

7. Керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Кушымта 2
Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына
2022 елның 17 гыйнвары, № 4

ХӘБӘРНАМӘ (БЕЛДЕРҮНАМӘ) № ______

Кәрәкәшле авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф.И. А.и.
_____________________________________________________________________________

Адресы: _______________________________________________________________

Гражданнар җыены карары нигезендә _________торак пунктында 2022 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге советы утырышы нигезендә, Сезгә _______ елга кадәр гражданнар җыены чараларын тормышка ашыру өчен _____ сум күләмендәге бер тапкыр түләнелә торган акчаны түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк:
Банк получателя
БИК

Получатель
Сч. №
ИНН КПП
КБК
ОКАТО
Түләү билгеләнеше
Гражданнарның үзара салым акчасы

Җитәкче _________________ ________________________________________
М. У. (имза) (имзаның расшифровкасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү линиясе** - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Белдерүнамә) № _________________
Кәрәкәшле авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча________________ сум күләмендә бер тапкыр түләнелә торган акчаны түләү турында
(*муниципаль берәмлек исеме*)

Түләүченең Ф.И. А.и. _______________________________________________________
Адресы: _____________________________________________________________________
Кабул ителде «__» _______________ 20__ елда ____________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Әгәр дә хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылса, өзелмә төпсә (отрывной корешок) тутырыла һәм Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитетында калдырыла.*